КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 февраль г.Казань № 87

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов истәлеген мәңгеләштерү турында» 2020 ел, 28 декабрь, 1200 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов истәлеген мәңгеләштерү турында» 2020 ел, 28 декабрь, 1200 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Советлар Союзы Геройларының, Социалистик Хезмәт Геройларының, Россия Геройларының һәм Татарстан Республикасы Сугыш һәм Хезмәт Даны орденнарының тулы кавалерларының иҗтимагый хәйрия оешмасы тәкъдимнәрен кабул итәргә:

Казан шәһәре, Горький урамы, 3Б йорт адресы буенча йорт фасадына Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецовка татар һәм рус телләрендә түбәндәге текст белән мемориаль такта кую турында, ул анда 2015 елның 5 июненнән 2020 елның 11 ноябренә кадәр яшәгән:

«Бу йортта
2015 – 2020 елларда
Советлар Союзы Герое
Борис Кириллович Кузнецов
яшәде

________

В этом доме
в 2015 – 2020 гг. жил
Герой Советского Союза
Борис Кириллович Кузнецов»;

«Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемендәге Казан кадет интернат-мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе территориясендә Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецовның бюстын урнаштыру турында.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин